“АРЧА 1 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ”

Әти-әниләр һәм балалар өчен татарча газета

# ЧИШМӘ БАШЫ

Ноябрь, 2024 нче ел

## 24 нче ноябрь—ӘНИЛӘР КӨНЕ

**Сабыр, изге күңелле, тормышның кояшы булган газиз әниләребез! Сезне матур бәйрәм белән чын йөрәктән тәбрик итәбез. Алдагы тормышыгызда сәламәтлек, җан тынычлыгы белән, балаларыгызның, туганнарыгызның янәшәсендә куанычлы, бәрәкәтле гомер итүегезне телибез. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай елмаеп, кешеләрне сөендереп яшәгез!**



### Бүгенге санда

« Әни—ул бәхет”
бәйгесе……………………....2 бит
Язучы белән очрашу………..2 бит
Республикакүләм семинар….3 бит
Әниләр көне…………………4 бит
Балалар өчен уеннар…………6 бит
Безнең уңышларыбыз……….5 бит
Балалар һәм әти-әниләр
өчен …………………………6 бит

## Безнең турында мәгълумат

*Игътибар итегез*

- Олимпиада нәтиҗәләре
- ГТО нәтиҗәләре
- Татарча кроссворд
- Әти-әниләр һәм балалар өчен уеннар

Адрес: Татарстан Республикасы,

Арча шәһәре,

Зур урам, 77,йорт, 1Н кв.

ds1.arsk@tatar.ru

**Бүгенге чыгарылышны әзерләде:**

Төхфатуллина Эльвира Рафисовна—өлкән тәрбияче

Камалиева Гөлназ Рәисовна—татар теле тәрбиячесе

# Әни- ул бәхет

Ноябрь аенда бакчабызда «Әнием-бәхетем» дип исемләнгән бәйге булып узды. Бу бәйгедә һәр төркемнән берешәр әни катнашты. Алар һәрберсе зур тырышлык белән. иҗади яктан сокланырлык дәрәҗәдә әзерләнгән иде. Әниләр тамашачылар игътибарына бәйләнгән кул эшләре, үзләре ясаган рәсемнәр, алмаз мозаикасы ярдәмендә эшләнгән чигүләрен, гаилә күренешләре сурәтләнгән фотоколлажларын тәкъдим иттеләр. Шигъри юллар белән үзләренең гаиләләре, тормышы, балалары, шөгыльләре белән таныштырдылар. Җиңүче исеменә уртанчылар төркеменнән **Гөлнара Рафил кызы** лаек булды. Әниләребезгә ныклы сәламәтлек, аяз матур көннәр һәм балалар бәхетен күреп, озак яшәүләрен телибез!





**Гөлнара Рафил кызы** бик күп кул эшләре остасы икәнен исбатлады. Гаиләсе белән бергәләп татар халкының милли ризыгы– итле бәлеш пешерү серләренә өйрәтте. Матур видео төшереп, тамашачыларга да осталык дәресе үткәрде. Аның һәрбер чыгышы матур шигырь юллары белән үрелеп барды. Без аңа киләчәктә тагын да зур уңышлар телибез.



## Якташ шагыйрәбез—Гөлчирә Нәҗметдинова



Арчаның 1 нче балалар бакчасына балалар шагыйрәсе Гөлчирә апа Нәҗметдинова очрашуга килде. Балалар бу көнне бик көтеп алдылар. Алар шагыйрә апаларының шигырьләрен өйрәнеп, берсеннән – берсе кызыклы сораулар әзерләп куйдылар. Ә инде аның үзен күрү, ягымлы тавышын ишетү, якыннан аралаша алуыбыз - безнең өчен аеруча кадерле. Шагыйрә үзенең балачак хәтирәләре белән уртаклашты, балаларга киңәшләрен бирде, теләкләрен җиткерде, әле яңа гына язылган шигырьләрен укыды. Аның шигырьләре фантазиягә, тирән фикергә бай. Балалар телен аңлап язылган. Шагыйрә аерым шигырьләрендә акыллы булырга, тәртипкә һәм хезмәткә өйрәтә. Аның йөрәк түреннән чыккан әсәрләре киләчәк буынны тәрбияләүдә һичшиксез зур урын алып тора. Һәр төркем балалары сәнгатьле итеп шигырьләрен сөйләделәр, җырладылар, биеделәр.

Шагыйрә белән очрашу күңелгә ятышлы истә калырлык булды, балалар яхшы кәеф алды. Очрашу истәлеге итеп, Гөлчирә апа үзенең китапларын безгә бүләк итеп бирде.

# Республикакүләм семинар

20 нче ноябрь көнне бакчабызда "Балалар бакчасында милли-төбәк компонентын тормышка ашыру юллары" темасы астында республикакүләм семинар булып узды. Кукмара, Теләче, Әтнә районнарыннан килгән тәрбиячеләр тәҗрибә уртаклаштылар. Әлеге семинарда мәгариф идарәсе методисты Иманаева Алина Радиковна һәм Г. Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте укытучысы Төхфәтуллина Әлфия Госмановна да катнашты. Балалар тарафыннан "Теремкәй" әкияте, "Кучтәнәчтә кунакта" эшчәнлеге, "Мендәр тутыру" һәм "Чәй эчү" йолалары, "Сабантуй" бәйрәмнәре күрсәтелде. Семинар күңелле уеннар, мастер-класслар, кунакларның кызыклы чыгышлары белән үрелеп барды.



**«Мендәр тутыру» йоласы**



**“Куян күчтәнәче»**



**«Сабантуй бәйрәме»**



**“Кулъяулык салыш» уены**





**Осталык дәресе**

**«Милли хәзинә»**



**“Теремкәй» әкияте**



**“Чәй эчү» йоласы**



**“Кучтәнәчтә кунакта»**

# Әниемнең җылы кочагы



**Уртанчылар төркемендә "Мин әнине яратам!" дип исемләнгән бәйрәм кичәсе булды**.

Бәйрәмгә әниләр, дәү әниләр һәм әбиләр дә килгән иде. Кадерле әниләренә багышлап балалар җырлар җырладылар, шигырьләр сөйләделәр. Әниләр белән бергәләп күңелле уеннар да уйнадылар. Бәйрәм ахырында үзләре ясаган матур чәчәкләрне бүләк иттеләр.



**Кечкенәләр төркеменә йөрүче балалар кадерле әниләренә матур бәйрәм чарасы оештырды**. Әниләр үзара җитезлектә көч сынашты-лар,әкиятләрне ни дәрәҗәдә белүләрен исбатлап күрсәттеләр, үзләренең иң яхшы әни исеменә лаек икәнлекләрен расладылар.
Чара балалар тарафыннан башкарылган шигырьләр, җыр-биюләр белән үрелеп барды.Бәйрәм ахырында балалар әниләренә үз куллары белән ясалган тәбрикләү открыткалары тапшырдылар. Алда тагын очрашулар, күңелле мизгелләр күп булсын иде дигән теләктә калабыз.



Салкын кышларга кереп барганда, без иң җылы һәм якты бәйрәмнәрнең берсен -Әниләр көнен билгеләп үтәбез.
Безгә тормыш бүләк иткән,бөтен йөрәк җылысын биргән,безнең өчен тынгысыз көннәр, йокысыз төннәр кичергән гәзизләребезгә нинди генә теләкләр теләсәк тә әз булыр сыман.Тормышыбыз бизәге булган әниләребез матур да, батыр да,мәрхәмәтле дә. **Беренче өлкәннәр төркеме әниләре, әниләр көненә багышланган музыкаль кичәгә җыелдылар**.Бәйрәм конкурс формасында узды.Әниләргә дә балаларга да бәйрәм бик ошады.



**Мәтәпкә әзерлек төркемендә әниләр көненә багышланган бәйрәм кичәсе булып узды**. Бәйрәмгә хөрмәтле әниләребез килгән иде. Кичә җырлар, шигырьләр һәм уеннар белән үрелеп барды. Балалар Абдулла Алишның "Куян кызы" әкиятен сәхнәләштереп күрсәттеләр. Бәйрәм ахырында балалар үз куллары белән ясаган бүләкләрен иң якын кешеләренә тапшырдылар. Килгән кунаклар да, катнашучы балалар да бик канәгать булып калдылар.



**Бүген икенче зурлар төркемендә әниләр бәйрәме булып узды.**
Бәйрәм гадәти булмаган формада - Сабантуй бәйрәме булып үткәрелде. Балалар матур шигырьләрен сөйләделәр, җырладылар һәм биеделәр. Әниләр рәхәтләнеп балалары белән төрле конкурсларда катнашып күңел ачтылар. Бәйрәм күтәренке рухта барды, бик күңелле узды.

# Безнең уңышлар



14 нче ноябрь көнне «Татарча сөйләшәм» олимпиадасының муниципаль этабы булып узды. Анда Арча районы балалар бакчаларында тәрбияләнүче мәктәпкә әзерлек төркеме балалары катнашты. 20 нче ноябрь көнне олимпиадага нәтиҗә ясалды һәм бүләкләү тантанасы булып узды. Бу бәйгедә безнең бакчабыздан **Сафина Ясминә һәм Гайфуллин Данил** катнаштылар. Сафина Ясминә 3 нче урынга, Гайфуллин Данил лауреат исеменә лаек булдылар. Афәрин, нәниләребез! Киләчәктә дә туган тел сагында торучылар булып, туган телебезне хөрмәт итеп яшәгез!



Мәктәпкә әзерлек төркеме тәрбияләнүчеләре **Гайфуллин Данил һәм Сабирова Ильмира** "Хезмәткә һәм оборонага әзер" Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәүдә катнаштылар.
Балалар тизлек мөмкинлекләрен, чыдамлык дәрәҗәсен билгеләү буенча барлык сынауларны уңышлы үтәделәр. Балалар һәр күнегүне зур тырышлык белән башкардылар , барлык нормативларны үтәгәндә яхшы физик әзерлекләрен күрсәттеләр.Алар бу мөһим чарада шатланып катнаштылар һәм 2 урынны алдылар! Аларны җиңүләре белән котлыйбыз!





27 нче ноябрь көнне Арчаның 5 нче балалар бакчасында район буенча тәрбиячеләр мастер-класс күрсәттеләр. Барлыгы 17 тәрбияче катнашты. Безнең балалар бакчасыннан **Ибрагимова Ләйсән Ягъфаровна** әлеге бәйгедә катнашып 3 нче урынга лаек булды. Ул милли бизәкле изү бизәү темасы белән чыгыш ясады. Ләйсән Ягъфаровнага киләчәктә тагын да зур уңышлар телибез!



МБМБУ "Арча 9нчы балалар бакчасы" нда 1 нче октябрь- Халыкара өлкәннәр көненә багышланган районкүләм "Супер әби, супер бабай" бәйгесе узды. Әлеге бәйгедә бакчабызның данын яклап уртанчылар төркемендә тәрбияләнүче Шакиров Әмирнең әбисе **Гөлфия Сәлихҗан кызы** чыгыш ясады. Татар халкына хас булганча, бик тыйнак та, сөйкемле дә, уңган да безнең Гөлфия әбиебез. Үзенең гомер юлы, балалары турында шигырь юллары аша таныштырды ул. «Сабантуй» күренешендә бик оста биюче икәнен исбатлады һәм «Иң мили җанлы әби» номинациясендә җиңү яулады Гөлфия Салихҗан кызы. Аңа иңади уңышлар, бәрәкәтле матур тормыш телибез!

## Татарча кроссворд

1. **Әниләрнең изге теләге.**
2. **«Семья» сүзенең татарча тәрҗемәсе.**
3. **Бала йоклый торган урын.**
4. **Кояш гомере……. мин әнием сиңа.**
5. **Өйнең нуры …..беләң.**




## Рәхәтләнеп уйнагыз!

Почмак алыш

Уенның максаты: балаларның сөйләм күнекмәләрен үстерү, аларда уяулык, җитезлек сыйфатлары тәрбияләү.
Балалар мәйданчыкның төрле урыннарында басып торалар. Алар — «әбиләр». Бер бала, «әбиләр» янына килеп, мунча сорап йөри:
— Әби, мунча бир әле?
— Мунчам буш түгел әле.
— Әби, мунча бир әле?
— Ташы төшкән.
— Әби, мунча бир әле?
— Мунча салырга агач юк. (Шулай итеп, төрле сәбәпләр әйтелә.)
Аннары тиз генә: «Һоп, һоп!» — дип, берничә мәртәбә кычкыралар. Шушы вакытта балалар урыннарын алыштыралар.

Мунча сораучы бала шушы арада берәрсенең урынын алып өлгерергә тиеш. Кем урынсыз кала, шул уенны дәвам итә.